**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ МОРДОВСКО-АФОНКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423103, Мордовское Афонькино село, Цаплина ул., 19 дом

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**МОРДВА АФОНЬКӘСЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423103, Мордва Афонькэсе авылы, Цаплин урамы, 19нче йорт

тел. (84396) 3-48-29, факс: (84396) 3-48-49, email: Mord.Cmn2@tatar.ru

№ 92 2018 елның 13 ноябреннән

# КАРАР
## Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 апрелендәге 79 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 26 статьясы, «җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын (2018 елның 24 апрелендәге 281 номерлы, 2018 елның 14 июлендәге 481 номерлы, 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 апрелендәге 79 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәткәрләрнең, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында:

«Мордва Афонькәсе авыл җирлеге башлыгы өчен түләү» I бүлегендә 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «3. Мордва Афонькәсе авыл җирлеге башлыгына ай саен акчалата түләү түләнә. Күрсәтелгән затларның хезмәт өчен түләү чыгымнарының айлык акчалата түләү өлешендә күләме авыл җирлеге башлыгы өчен елына 6,72 айлык акчалата бүләкне тәшкил итә торган нормативтан артмаска тиеш».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуын билгеләү 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Чирмешән муниципаль районы ТР
муниципаль районы Мордва Афонькәсе
авыл җирлеге башлыгы, советы рәисе А.И. Митяев